**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.07.2022 **Чирмешән авылы** **№191**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**территориясендә стационар булмаган**
**сәүдә объектларын урнаштыру**
**схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
№ 191, 04.07.2022 ел,

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру
схемасы

| Реестр № | Стационар булмаган сәүдә объектларының атамасы һәм урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектларының тибы (павильон, киоск, автолавка, лоток, һәм башкалар) | Мәйдан, кв.м. | Сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалану турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Чирмешән авылы, М.Титов урамы, 25Б бинасы янында | Азык-төлек товарлары | Павильон/киоск/ тонар/лоток | 40 кв. м. кадәр | сәүдә |